Алга, белем иленә!

# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының
78 нче лицей «Фарватер» укучыларының нәфис басмасы

2018 нче ел, 1 нче сан

Әлеге санда

1 нче сентябрь - Белем бәйрәме (1-2 нче бит)

Таныш булыйк (3 нче бит)

Сайлаулар (4 нче бит)

1 нче октябрь - Өлкәннәр көне (6 нчы бит)

Лицей хәбәрләре (4, 5, 7, 8, 9 нчы битләр)

Киләсе санда (10 нчы бит)

## 1 НЧЕ СЕНТЯБРЬ—БЕЛЕМ БӘЙРӘМЕ!



1 нче сентябрь - Белем бәйрәме! Бу көн – тәүге тапкыр мәктәп бусагасын атлаучылар өчен дә, кабаттан парта артына әйләнеп кайтучылар, укытучылар өчен дә зур бәйрәм!

Белем көне - ул чәчәкләр һәм ак тасмалар бәйрәме. Күпләр бу бәйрәмне "Беренче кыңгырау" бәйрәме дип тә йөртәләр. Ап-ак тасма бәйләгән, кулларына кечкенә портфель тоткан укучылар беренче тапкыр белем йорты бусагасын атлап керә, беренче укытучылары белән очраша.



# БЕЛЕМ БӘЙРӘМЕ!

Күп гасырлар дәвамында нәкъ менә бу көнне укучылар иртән-иртүк мәктәпкә беренче булып килергә ашыгалар. Шулай булуга карамастан, укучыларны инде алардан да иртәрәк килгән укытучылар каршы алалар. Бу уку елы да нәкъ шулай башланды...

Белем көне - укытучылар белән укучылар бәйрәме генә түгел. Белем көне әти-әниләр өчен дә, студентлар өчен дә, аң-белемнәрнең дөньяда иң зур байлык икәнен аңлаган кешеләр өчен дә зур бәйрәм!

Әлеге бәйрәм белән барлык укытучыларыбызны, лицеебыз укучыларын котлыйбыз! Укыту-укуда зур уңышлар, алган белемнәрнең файда алып килүен телибез!



















*Инсафетдинов Эмиль*

# ЛИЦЕЕБЫЗНЫҢ ЯҢА УКУЧЫЛАРЫ

Менә тагын җәйләр узды һәм сагынып көтеп алган 1нче сентябрь – Белем бәйрәме килеп җитте. Бу көнне һәрберебез дулкынланып, шатланып каршы ала: беренче тапкыр мәктәпкә баручы да, өлкән сыйныфларда укучы да, әти-әниләр дә.

Бу көнне 1 нче сыйныфка килүчеләр аеруча зур түземсезлек белән көтеп алдылар. 78 нче лицей "Фарватер" укучылары буларак алар бүген беренче адымнарын ясадылар. Аларны беренче кыңгырау бәйрәмнәре белән чын күңелдән котлыйбыз!

*Загидуллин Ринат*













# САЙЛАУ НӘТИҖӘЛӘРЕ

22 сентябрь көнне лицеебызда президент һәм төрле юнәлешләрдә министр вазифасын башкаручылар сайлавы булып узды. Кандидатлар алдан ук сайлау алды программалары белән таныштырды. Әлеге сайлауда катнашучыларга зур рәхмәтебезне белдерәбез!



Президент: Насыбуллин Марсель 61.6%









Мәгариф министры:
Зарипова Арина 38.8%

Спорт министры:
Амерханов Динар 65,82 %



Сәламәтлек саклау министры:
Сингаевская Яна 72,57%

Кадет сыйныфларының министры:
Бариев Радик 100%

Экология министры:
Васянова Варвара 85,65%



Папарацция министры:
Фараджева Айсу 100%

Куркынычсызлык министры:
Гатин Эмиль 100%

Мәгълүмат министры:
Искужина Ангелина 100%

Кадет сыйныфларының министры:
Бариев Радик 100%

*Загидуллин Ринат*

# «ӘКИЯТКӘ» СӘЯХӘТ



Без, 2 нче Г сыйныфы укучылары, 14 нче сентябрь көнне «Әкият» курчак театрының 85 нче юбилей сезоны ачылышына бардык! Курчак театры сезонны Ш.Перроның "Кот в сапогах" спектакле белән ачып җибәрде!

Спектакль алдыннан бәйрәмчә театральләштерелгән концерт оештырылган иде! «Кот в сапогах» спектакле онытылмаслык тирән, яхшы тәэсир калдырды! Әкияти декорация, матур күңелле музыка һәм әкият безне сокландырды! Сезгә дә барып карарга тәкъдим итәбез!





Сыйныф җитәкчебез Гарипова Гөлназ Рәис кызына һәм әти-әниләребезгә күңелле ял оештырганнары өчен бик зур рәхмәт!

*2Г сыйныфы укучылары*

## ХАЛЫКАРА ӨЛКӘННӘР КӨНЕ



Бу бәйрәм XX нче гасырда барлыкка килә. Иң беренче бу бәйрәмне Европада, аннан Америкада, ә инде 80 нче елның ахырында бөтен дөньяда бәйрәм итә башлыйлар.

1990 нчы елның 14 декабрендә безнең илебездә 1 Октябрь «Өлкәннәр көне» итеп игълан ителә. Илебез буенча октябрь ае башында Өлкәннәр көне уздырыла. Төрле җирләрдә өлкәннәрне котлаулар, бүләкләүләр, искә алулар бара.

Хөрмәтле өлкәннәребез! Сезне Халыкара өлкәннәр көне белән чын күңелдән тәбрик итәбез! Ныклы сәламәтлек, якыннарыгыз һәм

## ЯХШЫ ҮРНӘК

Безнең шәһәрдә яшиләр
Җитез әби-бабайлар.
Безнең кебек өлгер алар,
Безнең кебек сабыйлар.

Шул әбиләр бер елмайса,
Күтәрелә кәефләр.
Яннарында уйнап йөри
Нәни генә оныклар.

Үтсен әйдә, еллар үтсен,
Картаймасын күңелләр
Һәр көн яңа бәхет килсен
Үссен гөрләп бәбиләр.

Безнең дә бар картаясы,
Булышыйк өлкәннәргә.
Яхшы гамәлгә өйрәник
Карап бабай-әбигә.

*Миндубаева Альбина*

## ИЗГЕ ЭШ

8 нче сентябрь көнне лицеебызда матур традициягә әйләнгән Ярдәм Ярминкәсе үткәрелде. Ярминкәдә һәрбер сыйныф активлык күрсәтте. Сатып алучыларга үз куллары белән эшләнгән эшләнмәләр, уенчыклар, ризыклар тәкъдим иттеләр. Әти-әниләргә, килгән кунакларга аралашу, ял итү мөмкинлеге тудырылды.

Җыелган акчалар инвалид бала – Сахаров Иванга тапшырылачак.

## ФАЙДАЛЫ ОЧРАШУ

6 нчы сентябрь көнне юл йөрү кагыйдәләрен белү буенча профилактик чара уздыру максатыннан ЮХИДИ инспекторы Набиуллин Р. Р. белән очрашу үткәрелде. Инспектор башлангыч сыйныф укучылары белән юл хәрәкәте иминлеге буенча профилактик әңгәмә үткәрде. Шулай ук укучылар «Юл кагыйдәләрен һәркем белергә тиеш» уен-конкурсында катнаштылар. Конкурс юл хәрәкәте кагыйдәләрен, светофор сигналларын, җәмәгать транспортында һәм юлда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белүгә багышланган иде.

*Амерханов Динар*

## УКЫТУЧЫМА

Хәтерлим мин әле бүгенгедәй,
Сентябрьнең бере җиткәнен.
Хәтерлим мин әле бүгенгедәй,
Көтә-көтә арып беткәнем.

Иң беренче булып килим диеп,
Өскә матур күлмәк киеп.
Хәтерлим мин әле бүгенгедәй
Ашыга-ашыга чыгып киткәнем

Ләкин миннән бик күп алда килеп,
Хуш киләсең, әйдә, әйдә диеп.
Хәтерлим мин әле бүгенгедәй
Укытучы апам көткәнен.

Шушы көннән башлап безнең өчен
Кызганмады узенең бөтен көчен.
Безне сөйде, безгә белем бирде
Рәхмәт аңа изге эше өчен.

*Энҗе Мәэминова*

## УКУЧЫЛАР БӨТЕНРОССИЯ ОЛИМПИАДАСЫНЫҢ МӘКТӘП ЭТАБЫ

ШКОЛЬНЫЙ ЭТАП
Всероссийской олимпиады школьников

25 нче сентябрь көнне – лицей укучыларының Бөтенроссия олимпиадасының мәктәп этабы башланды.

Һәр икенче дәрәҗәгә эләгү өчен олимпиада оештыручылары тарафыннан билгеләнә торган баллар бусагасын узарга кирәк. Муниципаль этап 7-11 нче сыйныф укучылары өчен каралган, ә төбәк һәм йомгаклау ярышларында 9-11 нче сыйныф укучылары катнаша ала. Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында яхшы нәтиҗәләр күрсәткән укучыларга БДИ яки портфолиога өстәмә баллар яисә профильле вузларга имтихансыз керүгә мөмкинлекләр ачыла.

## ФАЙДАЛЫ ОЧРАШУ

В. Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университетының Интеграцияләнгән Менеджмент системалары кафедрасы доценты Репина Юлия Александр кызы белән очрашу узды. Ул монда Россиянең 44 төбәгеннән һәм 12 чит илдән 15 000 студент белем алуы, 2 000 тирәсе хезмәткәр эшләве турында сөйләде. Чыгарылыш сыйныф укучыларын бүгенге көндә университетта эшләп килгән юнәлешләр белән таныштырды.

## МИЛЛӘТЛӘР КРОССЫ—2018

15 нче сентябрь көнне узган Бөтенроссия «Милләтләр кроссы – 2018» һәм «Татарстан кроссы – 2018» ярышында Лицеебыз укучылары һәм укытучылары да катнашты. Әлеге чара бик күңелле, дусларча атмосферада узды һәм барлык катнашучыларга да ошады.

*Инсафетдинов Эмиль*

## МИН ЭТЛӘР ЯРАТАМ



Эт – акыллы, уяу һәм бик сизгер хайван. Акыллы эт хуҗасы әйткәнне тыңлый, ярдәм итә. Эт – кешенең тугры дусты.

Ничек яратмыйсың инде шундый тугры дусларны! Тик кешеләр кайвакыт үзләренең тугры дусларын ташлыйлар. Шәһәр җирендә хуҗасыз калган этләр ачлы-туклы яшәргә мәҗбүр булалар.Шундый этләрне күргәч, авыр булып китә. Мин аларны бик кызганам. Хуҗасыз этләрнең саны көннән-көн арта. Столбище поселыгында шундый этләр приюты бар икәнен белгәч, мин бик дулкынландым. Аларга тизрәк ярдәм итәсем килде. Лицеебыз укучылары аларга ел да ярдәм итә. Без дә сыйныфташларым белән бу акциядә катнаштык.

*Хафизов Илнур*

## ЯРДӘМ ИТӘРГӘ АШЫК

Приют 2003 елның гыйнварыннан бирле эшли. Бу вакыт эчендә 500 дән артык эт коткарылган. «Ятимнәр йорты» бары тик игелекле һәм шәфкатьле кешеләр хисабына гына эшләп килә.

Хайваннарны коткару өчен кирәк әйберләр:

1) азык;
2) төзелеш материаллары;
3) хуҗалык инвентаре ;
4) волонтерлар.

Приют иртәнге 9дан кичке 4кә кадәр эшли.

*Мәгълүмат интернет челтәреннән алынды*

# КИЛӘСЕ САНДА

Сез иң гүзәл кеше икәнсез...

Яңа китапханә нәрсәләр беләр белән гаҗәпләндерер

Президент булу авырмы?

Җәннәт - әниләрнең аяк астында

Искенең файдасы, яки макулатура җыю ни өчен кирәк?

Күзге мизгелләр...

## Укучыларыбыз иҗаты




Морозов Ярослав




Мәрвәрова Камилә



Морозов Ярослав



Гыйлметдинова Лилия



Сәгъдиева Диләрә

Безнең адресыбыз: Казан шәһәре Идел буе районы «78 нче лицей «Фарватер»

(Ю. Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139 тел./ факс 268-58-61.

E-mail: school_7878@mail.ru

Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин: https://edu.tatar

**Мөхәррир:** *Загидуллин Ринат,*
*Инсафетдинов Эмиль,*
*Миндубаева Альбина.*
***Консультант:*** *Фәйзуллина Рәзилә Яудәт кызы.*